ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«30» июня 2023 ел № 182

«2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында юл эшләре» муниципаль программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 24.05.2021 елның 148 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында юл челтәрен норматив хәлгә китерү максатларында, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «2023 елга, 2024 - 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы бюджеты турында» 15.12.2022 елның 23-1 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы карарлары, «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының «2023 елга һәм 2024-2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы бюджеты турында» 15.12.2022 елның 23-1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 25.04.2023 елның 28-6 номерлы карары нигезендә, 023 елда муниципаль юл фонды акчаларыннан файдаланганда үзара хезмәттәшлек турында Килешү кушымтасына кертелгән үзгәрешләргә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында юл эшләре» муниципаль программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 24.05.2021 елның 148 номерлы карарына беркетелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында юл эшләре» муниципаль программасын раслау турында» 24.05.2021 елның 148 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 27.06.2022 елнын 154 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре

порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (http://agryz.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкчесе** **Л.Ф. Нургаянов**

Татарстан Республикасы Әгерҗе
муниципаль районы Башкарма
комитетынын 30.06.2023 елның 182
номерлы карары белән расланды

**«2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында юл эшләре» муниципаль программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 24.05.2022 елның 148 номерлы карарына үзгәрешләр**

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында юл эшләре» муниципаль программасын раслау турында» 24.05.2021 елның 148 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.Карарның 2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2. 2023 елга Әгерҗе муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге юлларында юл эшләре программасына кертелгән җирле әһәмияттәге объектлар исемлеген расларга (кушымта итеп бирелә)»;

1.2.«2023 елга Әгерҗе муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге юлларында юл эшләре программасына кертелгән җирле әһәмияттәге объектлар исемлеген» дигән карарга кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә:

**2023 елга Әгерҗе муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге юлларында юл эшләре программасына кертелгән җирле әһәмияттәге объектлар исемлеге**

| Т/с | Объектның аталышы | Куәте км, пог.м, кв.м | амәлдәге бәяләрдә капитал салулар, мен сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Әгерҗе шәһәре, Ометов ур. 11,13,15,17,17а, Октябрьская ур. 4,6,8,10,12,13 | 1786,762 | 2256,784 |
| 2. | Әгерҗе шәһәре, М. Җәлил ур. | 208 | 1875,522 |
| 3. | Әгерҗе шәһәре, Яшьләр ур. (ЩПС) | 355 | 5615,712 |
| 4. | Әгерҗе шәһәре, Красноармейская ур. | 306 | 5044,008 |
| 5. | Сарсак-Умга авылы, К.Маркс урамы | 550 | 11807,974 |
| **МДФ планы буенча 2022 елга** | | | **26 600,000** |
| I. | 2021-2022 еллар бюджет йөкләмәләрен үтәү | | |
| II. | БДД буенча гамәлләр иректе калдыклар исәбеннән, шул исәптән: | | |
| 1 | Әгерҗе шәһәрендә Әгерҗе - Кр.Бор автомобиль юлы буйлап җирле әһәмияттәге автомобиль юлында тротуар төзү | 494 м | 5 018,92818 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **МДФның факттагы калдыгы буенча 01.01.2023 елга** | | | **5 018,92818** |
| 1 | Әгерже шәһәре урамнары чокырын ремонтлау | | 642,28 |
| 2 | Әгерже шәһәрендә юл билгеләре | | 775,79572 |
| **Программа буенча барлыгы** | | | **33 037,0039** |